ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЯТМАС-ДУСАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

“20” декабрь 2023 ел №31

Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрель 7 нче номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. . Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрель 7 нче номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә ((2018 елның 07 ноябре 26 нчы номерлы, 2019 елның 15 маендагы 6 нчы номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 7 нче номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 6 нчы номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 12 нче номерлы, 2023 елның 27 февралендагы 3 нче номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекнең 11 нче пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга

1.2. 4 нче бүлекнең 18 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәргә классы чин бирү турында карар, әлеге бүлекнең 12 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгына классы чин бирү турындагы тәкъдимнәр кертелгәннән соң, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Ятмас-Дусай
авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Гарифуллина